| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**19.04.2021** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№839** |

2021 елга гражданнар кеременең һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләмнәрен раслау турында

2007 елның 13 июлендәге «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 07 ноябрендәге 85-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, әлеге закон кушымтасында бирелгән Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданинга туры килә торган керемнең, гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче гражданин милегендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күрсәткечләрен билгеләү методикасы нигезендә, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Россия Федерациясе буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының 2021 елның беренче яртыеллыгына бәясе нормативы һәм Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар хакы күрсәткечләре турында» 2020 елның 24 декабрендәге 852/пр боерыгы белән, шулай ук Торак кодексының 49, 51 статьяларына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2021 елга гражданнарны аз керемлеләр дип тану турында карар кабул итү өчен түбәндәге иң чик күрсәткечләрне билгеләргә:

1.1. гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле милек хакының иң чик күләме:

1.1.1. ялгыз яшәүче граждан өчен-1 779 327 сум;
1.1.2. ике кешедән торган гаилә өчен-2 264 598 сум;
1.1.3. өч кешедән торган гаилә өчен-2 911 626 сум;
1.1.4. дүрт кешедән торган гаилә өчен-3 882 168 сум;
1.1.5. биш кешедән торган гаилә өчен – 4 852 710 сум;
1.1.6. алты кешедән торган гаилә өчен-5 823 252 сум;
1.1.7. җиде кешедән торган гаилә өчен – 6 793 794 сум.

1.2. гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләме:

1.2.1. ялгыз яшәүче граждан өчен-26 400,76 сум;

1.2.2. ике кешедән торган гаилә өчен-16 800,48 сум;

1.2.3. өч кешедән торган гаилә өчен – 14 400,41 сум.

2. «ЗМР Торак сәясәте департаменты» МКУ муниципаль торак фонды бүлегенә торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә куелганда, әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән иң чик күрсәткечләрне кулланырга.

3. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге начальнигына әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында һәм Интернет челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И. Р. Ганиев

**2021 елга гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләмнәрен билгеләү**

**МЕТОДИКАСЫ**

1. **Базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече**

**СЖ= НП*РС* РЦ, биредә**

СЖ-базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече яки мөлкәт хакының иң чик күрсәткече;

НП – гаиләнең бер әгъзасына торак урыны бирү нормасы;

РС-гаилә әгъзалары саны;

РЦ-РФ Төзелеш һәм торак - коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан расланган 1 кв. м мәйданның уртача исәп-хисап базар бәясе (2021 елның беренче кварталына – 53 919 сум)

а) ялгыз яшәүче граждан өчен:

СЖ= 53 919 *33= 1 779 327

б) ике кешедән торган гаиләгә:

СЖ=53 919 *42= 2 264 598

в) өч кешедән торган гаиләгә:

СЖ=53 919 *18*3= 2 911 626

г) дүрт кешедән торган гаиләгә:

СЖ=53 919 *18*4= 3 882 168

д) биш кешедән торган гаиләгә:

СЖ=53 919 *18*5= 4 852 710

ж) алты кешедән торган гаиләгә:

СЖ=53 919 *18*6= 5 823 252

з) җиде кешедән торган гаиләгә:

СЖ=53 919 *18*7= 6 793 794

**2. Гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең иң чик күләме**

**$ПД=0,7*СЖ*ПС/ ПС / (1+ПС)^{-КП}) /(0,3*РС)$, биредә**

СЖ-социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирү нормасы буенча торак урыны алу өчен базар хакының исәпләнгән күрсәткече;

ПС - кредит буенча бер ай эчендә процент ставкасы, (4,5/12)

КП - кредитның бөтен срогында кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны (240));

РС-гаилә әгъзалары саны;

0,7-кредит суммасы һәм фатир бәясе бәйләнеше;

0,3 — кредит буенча түләүнең гаиләнең айлык җыелма кеременә карата бәйләнеше;

а) ялгыз яшәүче граждан өчен:

$ПД=0,7*1\ 779\ 327 *0,0038 / (1-(1+0,0038)^{-240}) / (0,3*1) = 26\ 400,76$

б) ике кешедән торган гаиләгә:

$ПД=0,7*2\ 264\ 598 *0,0038 / (1-(1+0,0038)^{-240}) / (0,3*2) = 16\ 800,48$

в) өч кешедән һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаиләгә:

$ПД=0,7*2\ 911\ 626 *0,0038 / (1-(1+0,0038)^{-240}) / (0,3*3) = 14\ 400,41$

г) дүрт кешедән һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаиләгә:

$ПД=0,7*3\ 882\ 168 *0,0038 / (1-(1+0,0038)^{-240}) / (0,3*4) = 14\ 400,41$

«Зеленодольск муниципаль районы
торак сәясәте департаменты» МКУ җитәкчесе Н. Н. Минһаҗев